Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　КАРАР

07.04.2021　　　　Менделеевск ш.　　　　№ 244

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендәге
административ җәзаларны үтәү өчен
мәҗбүри эшләр төрләрен һәм
оешмалар исемлеген билгеләү турында

Россия Федерациясе Административ хокук бозулар кодексының 32.13 статьясы нигезендә, мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәзаларны үтәү өчен шартлар тудыру максатыннан, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә административ җәзаларны үтәтү өчен мәҗбүри эшләр төрләрен расларга.

2. 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәзаларны үтәтү оешмалары исемлеген расларга.

3. Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Менделеевск һәм Тукай районнары буенча бүлегенә мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәзалар үтәүче оешмаларга хокукый һәм методик ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Норматив документлар» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http//pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче　　　　Р.А.Абдуллин

Килештерелде:
Юридик бүлек башлыгы　　　　Е.С.Царева

1 нче кушымта<br>Татарстан Республикасы<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Башкарма комитетының<br>2021 елның 7 апреленнән<br>244 нче номерлы карарына

Татарстан Республикасы<br>Менделеевск муниципаль районы территориясендә<br>административ җәза үтәү өчен мәҗбүри эш төрләре

1. Территорияләрне чистарту: территорияләрне чүп-чардан, кардан, бозлавыктан арындыру.
2. Биналарны җыештыру.
3. Чардак һәм подвал бүлмәләрен җыештыру.
4. Төяү-бушату эшләре.

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 7 апреленнән
244 нче номерлы карарына

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә административ
җәзаларны үтәтү оешмалары исемлеге

1. «Менделеевск муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалык идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе.
2. «Төзекләндерү идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе.
3. Татарстан Республикасы "Менделеевск муниципаль районының административ-хуҗалык учреждениесе" муниципаль бюджет учреждениесе.
4. "Нептун 1" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять.